**Шәһәр күләмендә Татарстан һәм татар халкы тарихы фәненнән**
**үткәрелә торган олимпиаданың**
**мәктәп этабы сораулары**
**2017-18 уку елы**

**10 нчы сыйныф.**

Биремнәрне үтәү өчен 3 сәгать вакыт бирелә.
Иң югары балл – 46 балл.

**1 бүлек. Тәкъдим ителгән җаваплар арасыннан дөресен сайлап алыгыз. 5 биремгә 1 әр балл (иң югары - 5 балл).**

**1. Түбәндәге шәхесләрнең кайсысы Казан ханы түгел?**
А) Сафагәрәй Б) Сәхибгәрәй В) Җангали Г) Җанибәк
Җавап: ____________

**2. Җучи Олысы ханнары тарафыннан рус кенәзләренә бирелә торган грамотаны ничек атаганнар?**
А) ярлык Б) пайцза В) басма Г) тархан
Җавап: _____________

**3. Сәед кем ул?**
А) борынгы төркиләрдә рухлар дөньясы белән арадашчы
Б) Мөхәммәд пәйгамбәр токымыннан чыккан югары руханилар катлавы вәкиле
В) Төркиләрнең күк алласы
Г) һуннарда идарәче
Җавап: _____________

**4. Танылган педагог һәм мәгърифәтче Ризаэтдин Фәхретдин чыгарган татар журналы:**
А) “Мәктәп” Б) “Шура” В) “Мәгариф”
Җавап: _____________

**5. Дәүләт думасының 2 нче чакырылышы кайсы вакытта җыела?**
А) 1914 ел, 6 декабрь Б) 1906 ел, 27 апрель
В) 1907 ел, 20 февраль Г) 1907 ел, 1 ноябрь
Җавап: _______________

**2 бүлек. Туры китерүгә, эзлеклелекне, артык элементны билгеләүгә нигезләнгән биремнәр. 5 бирем, 2 шәр балл (иң югары 10 -балл).**

**6. Тарихи шәхесне ул идарә иткән дәүләт белән туры китерегез:**

| Тарихи шәхес | Дәүләт |
|---|---|
| 1) Аттила | А) Хун дәүләте |
| 2) Бумын | Б) Җучи Олысы |
| 3) Үзбәк | В) Төрки каганлык |
| 4) Сафагәрәй | Г) Казан ханлыгы |
| 5) Модэ | Д) Идел Болгары |
| 6) Алмыш | Е) Гуннар дәүләте |

| | |
|---|---|
| | Ж) Себер ханлыгы |

Җавап:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |

**7. Түбәндәге җитәкчеләрне аларның идарә иткән вакытларына бәйле рәвештә хронологик эзлеклелектә урнаштырыгыз:**

А) Алмыш; Б) Кубрат; В) Батый;
Г) Җангали; Д) Сөембикә; Е) Олуг Мөхәммәд;
Ж) Билге каган.

Җавап: ______________________________

**8. Авторны һәм аның әсәрен туры китерегез.**

| Автор | Әсәр |
|---|---|
| 1) Г. Исхакый | А) «Хәят» (1911) |
| 2) С. Рәмиев | Б) «Сөнначе бабай» (1911) |
| 3) Ф. Әмирхан | В) «Банкрот» (1911) |
| 4) Г. Камал | Г) «Таң вакыты» (1908) |

Җавап:

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | |

**9. Галимне һәм аның фән үсешенә керткән яңалыгын туры китерегез:**

| **Галим** | **Фәнгә керткән яңалык** |
|---|---|
| 1) Гыйлем Камай | А) кабырчыкның заманча нәсызыкча теориясе |
| 2) Әбүбәкер Терегулов | Б) үзгәрүчән массалы механик системаларның хәрәкәт тотрыклылыгы |
| 3) Хәмит Мөштәри | В) фосфор һәм мышьяк кушылмалары |
| 4) Габделмәнгыйм Әминев | Г) эчке авырулар пропедевтикасы |

Җавап:

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | |

**10. Исемлектәге шәхеснең кайсысы әлеге рәткә туры килми?**

1) Галимҗан Баруди
2) Ризаэтдин Фәхретдин
3) Галимҗан Ибраһимов
4) Мөхәммәтҗан Хөсәенов

Җавап:______________________

**3 нче бүлек. Рәсемнәр белән эшләүгә нигезләнгән биремнәр.**

Рәсем белән эшләүгә нигезләнгән бирем (кем сурәтләнгән – 1 б., чор дөрес билгеләнгән – 1 б., әлеге сурәт белән бәйле вакыйга дөрес билгеләнгән – 1 б.; иң югары 3 балл).

**11. Түбәндәге сурәтне карагыз һәм сорауларга җавап бирегез:**



1. **Рәсемдә кем сурәтләнгән?**

______________________________________________________________

2. **Әлеге сурәт кайсы чорга карый?**

______________________________________________

3. **Бу шәхес турында ниләр әйтә аласыз?**

______________________________________________________________

**4 нче бүлек. Чыганак текстлары белән эшләүгә нигезләнгән биремнәр.**
**(2 чыганак, һәрберсенә 3 әр бирем, һәр биремгә 2-4 балл куела; <u>иң югары 18 балл).</u>**

**12. Текстны укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез:**

***Г.Ибраһимов. Татар мәдәнияте нинди юл белән барачак?***

*[...] Халыклар үзләренең телләре, гореф-гадәтләре, тормышлары, тарихи язмышлары буенча бер-берләреннән тышкы калыпларда байтак аерылалар. Шуңа карап аларның һәрберенең мәдәнияте, мәдәни хәрәкәте дә тышкы төстә үзенә башка аерым рәвештә гәүдәләнәләр. Мәсәлән, мәктәп, сәнгать, гыйлем, әдәбият – болар һәммәсе милләтнең үз телендә булырлар. Үз телендә киңәеп, тирәнәеп үсәрләр, үз хаҗәтләренә карашып туарлар, үзенә уңай, аңлаешлы калыпларга салынырлар, үз тормышы белән сугарылып, үзләренең аерым тарихи моментлары, тудырган мәсьәләләре юлында эшләрләр: менә бу яклар буенча үзбәкләрнең, урысның, казакъның, әрмәннең, татарның, грузинның, башкортның [...] мәдәниятләре бер-береннән бик нык аерылырлар, бу тышкы калыпларда һәр халыкның мәдәнияте үзенең милли нигезендә, үз ана телендә үз тормышының аерым хасиятләре белән сугарылыр, аерым рәвешләнер. Ләкин эчке идеологиядә төп нигез принципларда, алдагы максудларда бу төрле телдә, төрле төстә, төрле калыпта булган бу күптөрле мәдәниятләр һәммәсе берләшәләр: пролетариат революциясе аркылы коммунизмга бару, моның өчен интернациональ байрак астында, тел аермалыкларына карамыйча, киң эшче-крестьян коллективы буларак көрәшү. [...]*

*Милли мәдәният дигәннән, кәләпүш киеп, без өч йөз ел изелгән, дип, хәсрәт җыры җырлап йөрүне генә алу хата булачак. Шөбһә юк, милли мәдәниятнең төп элементлары эченә башлыча*

*халыкның үз тормышыннан алып, үз теле нигезендә, үз хаҗәтләренә каратып, үзе тарафыннан иҗат кылынган кыйммәтләр кирәчәк. Ләкин милли мәдәният чиген моның белән кыскарту бик зарарлы идеализм булыр иде.*
*Дөньяда һичбер халык башкалар белән алмашудан башка яши алмый. Тик товар алмашу гына түгел, техника, гыйлем, сәнгать, һөнәр, тәҗрибә, гадәт, методлар алышу мәдәни хәятта беренче рольне уйнаучылардан була.*

**Г.Ибраһимов "милли мәдәният" төшенчәсен ничек аңлый? (Тексттан мисаллар китерегез).**

___

___

___

**Чыганакта миллилек һәм интернационализм идеяләре ничек берләштерелә? (Тексттан мисаллар китерегез)**

___

___

___

___

___

**Сезнеңчә, милли мәдәният нинди критерийларга җавап бирергә тиеш?**

___

___

___

___

___

___

**13. Текстны игътибар белән укыгыз һәм сорауларга җавап бирегез.**

**Язучы Хатип Госманның фронттан хезмәттәшләренә язган хаты (1941 ел, 31 декабрь)**
*Ярми, Агиш, Хәй абый, Әмир, Җәләй ага һәм Шабанов! Сезгә фронттан Яңа ел сәламе!*
*Мин, миллионнар арасына кереп, сезнең күздән югалдым, ахыры, сездән ни сәлам, ни хәбәр юк. Ә мин, чынлап әйткәндә, югалмадым гына түгел, киресенчә, зур өметләр һәм күңелем тулы якты хисләр белән яңа 1942 елга атлыйм.*
*"Үлем немец оккупантларына!" – минә безнең лозунг. Нәкъ 700 ел элек, 1242 елда немецлар Чуд күлендә тар-мар ителгән булсалар, 1942 елда аларны тагын да рәхимсезрәк һәлакәт һәм тар-мар ителү көтә. Без җир йөзендәге барлык гүзәллекнең иҗат итүчесе – Кеше өчен сугыш алып барабыз, аның бөек иҗат җимешләрен – культураны һәлакәттән саклап калу өчен көрәшәбез. Бу авыр көрәш, ләкин безнең халыкның кодрәтле рухы бу авырлыкны җиңеп чыгар һәм бөтен халыкларга азатлык һәм тыныч тормыш алып бирер. Без моңа ышанабыз һәм 1942 ел безнең ышанычыбызны чынбарлыкка әверелдерәчәк.*
*Сәлам дуслар!*
*Безнең җиңү елыбыз башлану белән һәммәгезне дә чын күңелдән тәбрик итәм!*
*Сугышчы Хатип Госман.*
*Төньяк-Көнбатыш фронт.*

**Ничек уйлыйсыз, әлеге хатта автор нинди хисләрен белдергән? Ватанпәрвәрлек һәм һичшиксез җиңүгә ышаныч белдерелгән җөмләләрне күчереп языгыз.**

**“Культура” сүзен автор нинди мәгънәдә кулланган?**

**Интернациональ хисләр белдерелгән җөмләне аерып күрсәтегез (күчереп языгыз).**

**5 нче бүлек. Тарихи эссе.**

**14. Түбәндә тәкъдим ителгән темаларның берсен сайлап алып, тарихи эссе языгыз.**
**Күләме – 300 сүз тирәсе.**
**(Теманы дөрес ачкан өчен – 1 балл, тиешенчә китерелгән факт һәм даталар өчен – 2 балл, дөрес дәлилләр китергән өчен – 3 балл, төрле карашлар китергән һәм аларга шәхси бәя биргән өчен – 4 балл (иң югары 10 балл).**

1. **Идел Болгарында рәсми рәвештә ислам дине кабул ителүнең Идел буе халыкларының мәдәнияте үсешенә йогынтысы.**
2. **Җәдитчелекнең төрки халыклар мәгарифенә йогынтысы.**
3. **Каләмне штыкка тиңләп ... (Татар язучылары Бөек Ватан сугышы кырларында).**
4. **Ш.Мәрҗанинең фәнни-педагогик эшчәнлеге.**

**УҢЫШЛАР ТЕЛИБЕЗ!**